# Татар теленең язма корпусы һәм тел мәсьәләләре

Күңел күзе булмаса, маңгай күзе – ботак тишеге.
Халык мәкале

Корпусның Интернетка куелуына ике ай вакыт узды. Ара күп түгел, шулай да кайбер нәтиҗәләр ясарга урын бар. Корпус куелган сайтка керүчеләрнең саны 100-дән артмый. Димәк, корпус белән кызыксынучылар юк дәрәҗәсендә. Ә бит татар миллэтендә тел белгечләренең саны да, мөгаен, өч - дүрт йөзгә җитә торгандыр. Ирексездән Габдулла Тукай сүзләре искә төшә. Үзеннән-үзе: “Безнең телчеләребез йоклаганмы, әллә үз фәннәренә батканнармы?” – дигән сорау туа. Корпус, ул нинди генә булмасын, лингвистлар игътибарыннан читтә калырга тиеш түгел иде.

Корпус белән танышканнарның фикерләре төрлечә. Кайберәүләр аны кирәкле нәрсә дип тапмадылар. Дәрәҗәле галимнәрнең берсе төзелгән корпусны “тәгәрмәч ясау” формасындагы мәгънәсез хезмәт дип күрсәтергә тырышты. Күпләр хуплап каршы алдылар; тулыландырырга һәм функциональ планда баетырга киңәш иттеләр. Татар теленең язма корпусы төзелүгә безнең белән бергәләп шатланган галимнәр дә булды.

Фикерләрен әйткән шәхесләрнең һәркайсына рәхмәтлебез. Зур рәхмәтебезне корпуска мөнәсәбәтле семинар оештырган Татарстан фәннәр акдемиясе каршындагы “Тел, әдәбият һәм сәнгать институты” ның җитәкчелегенә, семинарда катнашкан иптәшләргә дә белдерәбез.

Язма корпус бүгенге чор татар тел дөньясын гәүдәләндерә. Бер үк вакытта ул шәхесләрне татар тел дөньясын анализлау – орфографиягә караган җитешсезлекләрне, сүзформалар, мәгънәләр төрлелеген барлау инструменты белән дә тәэмин итә. Язма корпуска хас тагын бер сыйфат – ул һәр сүзформаны, аның алдыннан һәм артыннан килүе мөмкин булган сүзләрне аларның очрау ешлыкларын чагылдырган саннар белән сыйфатлый. Санның сыйфатка күчү закончалыгын инкарь иткән тәгъүлиматның яратылганы юк. Димәк алдагы көннәрдә корпуста китерелгән зурлыклардан кайда һәм ничек файдалану мөмкинлекләрен өйрәнергә тиеш булабыз.

Студент чагымда тәнәфесләрнең берсендә танылган профессор Латыйп Җәләйнең: “Шәһәрдә яшәгән кеше белдерүләр укып та галим була ала”,- дигән сүзләре хәтеремдә калган. Өлкән яшьтәге олуг фикер иясе бу сүзләрне, мөгаен, “күңел күзе” булган шәхесне истә тотып әйткәндер. “Күңел күзе” булмаган шәхеснең (ул кайда гына яшәмәсен) белдерүләр укырга да, кызыксынырга да, гаҗәпләнергә дә, уйланырга да вакыты җитми. Ул шулай ук 45 миллионнан артык сүзкулланыш (словоупотребление), 400 мең төрле сүзформаны эченә алган текстлар

җыелмасын (язма тел дөньясын) күрмәскә дә мөмкин. Нигә, кызык өчен генә булса да, тел очында торган ике-өч сүзнең (әйтик *әни, әти* сүзләрен) милләт телендә ниди ешлык белән куллануларын үлчәп карамаска, ешлыклар арасындагы аермалыкны (тәңгәллекне) күреп бераз гына уйга калмаска?

Язма корпус төзелүнең уңай яклары аның тел дөньясын күзәтү инструменты тәшкил итүе белән генә чикләнми. Ул бер үк вакытта татар теле ресурсларын барлау, тел ияләренә алар белән өзлексез танышып тору (мониторинг ясау) мөмкинлекләре ача.

Татар тел дөньясы ни хәлдә? Аның җиһан төрлелеген гәүдәләндерү өчен җитәрлек ресурслары бармы? Ничек ул ресурсларның булган кадәресен имин килеш киләчәк буыннарга җиткерергә?

Сорауларга җавап йөзеннән тел дөньясының нәрсәдән гыйбарәт булуын бераз гына булса да ачыклап китү урынлы булыр.

Галимнәр күзаллавынча, кешеләр түбәндәге өч төр нәрсәләр дөньясында яшиләр: а) әйберләр/күренешләр һәм алар арасындагы мөнәсәбәтләр дөньясында, б) әйберләр һәм аларның үзара мөнәсәбәтләрен белдергән исемнәр дөньясында, д) әйберләр һәм аларның үзара мөнәсәбәтләренә карата урындагы һәм тарихи шартларда тел ияләре аңында яратылган психик корылмалар - модель-төшенчәләр дөньясында. Бу дөньялар үзара тыгыз бәйләнештә торалар, әмма бер-берсенә тәңгәл түгелләр.

Исемнәр дөньясы әйберләр дөньясын тәшкил иткән җиһанны чагылдыра. Татар тел дөньясы җиһанны ни дәрәҗәдә тулы гәүдәләндерә?

Бер караганда мондый сорауның куелуы урынсыз да кебек. Галимнәр әйтүенчә, һәр тел аерым мәдәният җирлегендә формалаша. Әмма мәдәният, аның белән бергә тел дә һәрдаим үзгәреп тора. Телләр бәрелешендә аерым мәдәният вәкилләре күрше халыкларның тормыш-көнкүрешенә хас үзенчәлекләр белән танышалар, үзләренә ошаганнырын, яшәү өчен файдалы булганнарын үз итәләр. Рухи һәм матди мәдәният яңалыклары белән бергә аларның исемнәре дә кабул ителә.

Телләрнең үзара бәйләнешендә өч хәл күзәтелергә мөмкин:

1. А һәм В телләренең үзара йогынтысыннан яңа бер тел, әйтик С теленең тууы (*мисал*: креол телләр),

2. А һәм В телләренең бер-берсе хисабына баюы, үсеше,

3. А теленең В теленә күчеше.

Чынбарлыкта күбрәк өченче очрак күзәтелә. Аның төп сәбәпләре икәү. Беренчесе - телләрнең үзара бәйләнешенә кешеләрнең кысылуы (“*шулай язарга”, “шулай әйтергә”*- дигән карарлар чыгару, телләргә төрле

статуслар бирү – *БМО эшен тәэмин итүче тел*, *милләтләр аралашуын тәэмин итүче тел*, *дәүләт теле*, *этнос теле*, *диалект*).

Икенчесе – аерым иҗтимагый, тарихи шартларда В теленең һәм мәдәниятенең престижлы мәдәният һәм престижлы телгә әверелүе.

Беренче төр сәбәпләр бүгенге көндә татар теленең рус теленә авышуында (языковой сдвиг) күзәтелсә, икенче төр сәбәпләр рус теленең инглиз теленә авышуында чагылыш таба.

Престижлы мәдәният престижлы тел белән берлектә хакимлек иткән чорда милли телләр котылгысыз хәлгә юлыгалар. Телгә яңа сүзләр керү чиктән тыш активлаша. Нәтиҗәдә милли тел вәкилләре башта ике телне бутап, соңрак престижлы телдә сөйләшүгә күчәләр.

Бүген шушы схемада рус теленең инглиз теленә күчүе, күңел күзе булган шәхесләр өчен, сер түгел. Соңгы елларда дөньяда чыккан фәнни мәкаләләрнең туксан проценттан артыгы инглиз телендә нәшер ителә. Үзләрен дөньяга танытырга омтылган интеллигенция вәкилләре хезмәтләрен инглиз телендә иҗат итүне, киң галәмгә чыгаруны хуп күрәләр. Чит телләр белән бәйләнештә торган структуралар хезмәткә инглиз телен белүчеләрне алырга тырышалар. Рус телендә чыккан журнал-гәзит битләрендә инглиз телен “киллер тел” дип атау күзгә чалына башлады.

Татар теленең рус теленә авышуы рус мәдәнияте тәэсиреннән тыш орфографиянең фәнни булмавына да бәйләнгән. 1940 еллардан бирле татар тел белемендә акылга сыймаган: “Алынма сүзләр рус телендәгечә язылa” дигән күрсәтмә хакимлек итә. Лексикографиядә күзәтелгән мәгълүматләргә карагандa, татар телендә табылган 26 мең сүзнең 12 меңе русча язылган алынмалардан тора. Татар теле бүгенге халәтендә, бер яктан, лексик берәмлекләргә бай, макро- һәм микродөньяларны, флора һәм фауна төрлелеген тасвирлауга сәләтле булса, икенче яктан, бу сүзләр җөмләләр әйтелешенә хас автоматизмны һәм, гомумән, сөйләм агышын имгәтәләр.

Автоматизм режимында башкарылучы процессларның төп сыйфаты - энергия чыгымын киметүдән гыйбарәт. Безнең очракта энергия чыгымын киметү - ул әйтелешне җиңеләйтүдән тора. Сүзнең яртысын русча яртысын татарча әйтү, билгеле, әйтелешне җиңеләйтүгә китерми. Киресенчә, киеренкелек тудыра. Шәхес сөйләмендә сагая, икеләнүләр кичерә, сөйләм әгъзаларын үз вакытында тиешле режимга көйләүне кайгырта. Шәхес бу хәлдән котылуны эзли, бераздан “танцы итү”не “танцеватька, “рекомендация”ләүне “рекомендовать” дип сөйләүгә күчә.

Кызганычка каршы, татар сөйләменең имгәтелүе артикуляция өлкәсе белән генә чикләнми. Алынмаларның 40%ка җитүе сөйләүчегә башка төр кыенлыклар да тудыра. Шуларның берсе – сөйләүченең җөмләләр әйтү процессында сүз таба алмый иза чигүе.

Психолингвистика тәгълиматендә сөйләм ятатылу дүрт этапка бүленә. Беренче этап, гадәттә, интенция этабы дип исемләнә. Бу этапта агымдагы хәлләр тәэсирендә фикер яратыла. Икенче этапта фикер нигезендә эчке сөйләм – төшенчәләр структурасы төзелә. Өченче этапта исә төшенчәләр аерым телгә хас лексик берәмлекләр, грамматик формаларга күчереләләр. Ул фикернең вербализацияләнү фазасын тәшкил итә. Дүртенче этапта сүзләр, грамматик формалар сөйләм әгъзаларына җиткереләләр һәм авазларга күчәләр.

Алда сау-сәламәт затларның сөйләме автоматик процесс тәшкил итә дип әйтелгән иде. Дөньякүләм танылган психолог Л.С.Выготский кеше башында туган фикерне (эчке сөйләм тәшкил иткән структураны) су белән тулган болыт формасында күз алдына китерә. Аның күзаллавынча, яңгыр башлану белән болыт суы тамчылар булып җиргә коелса, сөйләм башлану белән эчке сөйләм дә сүзләр, грамматик формаларга күчерелеп эфирга агыла.

Кызганыч ки, мондый агым татарлар сөйләмендә сирәк күзәтелә. Сөйләүченең фикере бар, әйтеләсе вакыйганы ул күз алдына ачык китерә. Әмма аны сүзләргә күчерүдә ул кыенлыкларга юлыга. Шәхеснең аң-фикер дөньясын төзүче төшенчәләр белән тел-исемнәр дөньясы (менталь лексикон) арасындагы бәйләнеш зәгыйфьләнгән. Сөйләүче хәтерендә ул төшенчәләрне белдерүче сүзләр таба алмый. Нәтиҗәдә автоматизм югала, сөйләм агымында өзеклелек барлыкка килә. Сөйләүче, уң аягына басканда сул аягының әле җирдән аерылмаган булуына охшаш уңайсызлык кичерә, фикерен көнкүрешендә ешрак ишетелүче рус сүзләрен кушып әйтә башлый. Алга таба, иза чигүләрдән туеп, руссчага күчә.

Сөйләүче юлыккан халәткә берникадәр ачыклык кертү өчен тел дөньясына кабат күз салыйк.

Алда кешеләрнең өч төрле нәрсәләр дөньясында яшәүләре, өченче төр дөньяның “әйберләр һәм аларның үзара мөнәсәбәтләренә карата урындагы һәм тарихый шартларда тел ияләрене аңында яратылган психик корылмалар - модель-төшенчәләр” булуы бәян ителгән иде. Модель-төшенчәләр, психик корылмалар буларак, психология фәненең өйрәнү объектын тәшкил итәләр. Әмма алар телдә чагылыш табалар һәм бүгенге көндә бары тик тел ярдәмендә күзәтелергә, өйрәнелергә мөмкиннәр.

Хәзерге чорда психик корылмалар “концептлар сферасы” исеме астында тел белеменең бер тармагын тәшкил иткән концептология фәнендә өйрәнеләләр.

Концептология фәнендә “концепт” – аң берәмлеге. Системалаштырылган һәм аерым бер тәртипкә салынган аң берәмлекләре – концептлар шәхеснең аң даирәсен – концептосферасын тәшкил итәләр. Шәхеснең концептосферасына керү, аның эчтәлеге, сыйфаты белән танышу бары тик тел ярдәмендә генә башкарылырга мөмкин.

Концептның мәгънәсе “смысл” (төшенчә) мәгънәсенә якын, әмма аңа караганда киңрәк. “Концепт” (төшенчә) термины аерым әйбер яки күренешнең шәхес аңында нинди эчтәлектә тасвирлануын белдерсә, “концепт-төшенчә” ул төшенчәгә карата шәхеснең мөнәсәбәтен, аның үзе өчен ни кадәр гыйбрәтле булуын да чагылдыра.

Аң берәмлеге буларак, концепт шәхеснең тормыш-көнкүрешенә, дөньяга карашына, табигатенә бәйләнештә формалаша. Аңлашыла ки, бер иҗтимагый шартларда, бер телдә аралашкан кешеләрнең концептлар даирәсендә уртаклык булмый калмый. Ул уртаклык концептология фәнендә аерым тел ияләренең – этносның концептлар даирәсе – концептосферасы буларак күздә тотыла һәм өйрәнелә.

Татар милләтенең концептлар даирәсе тарихи һәм социаль шартларда, ислам дине һәм телнең лексик, грамматик чаралары нигезендә формалашкан. Шәхеснең, теге яки бу этносның тел дөньясы, тел аңы, фикерләве психолингвистика, когнитивная лингвистика, концептология дип исемләнгән тел белеме тармакларында өйрәнелә. Өйрәнү ысулы, нигездә, тел үзе. Аңның нәрсә тәшкил итүен, фикерләүнең ничек оештырылуын бүгенге шартларда бары тик тел мисалларында гына күзәтергә мөмкин. Югарыда әйтелгәннәргә үрнәк формасында һәм, бер үк вакытта, язма корпусның кулланылу мөмкинлекләрен күрсәтү нияте белән ике мисал китереп үтәбез.

Нәрсә ул аң берәмлеге, аерым алганда, мәсьәлән, “**үлем**” концепты?

Дөнья барлыкка килгәннән бирле кешенең зиһенен чуалдырып, кешене уйландырып, куркытып, тәртипләндереп, нәфесен тыеп килгән күренешләрнең берсе – “үлем” вакыйгасы. Ислам дине һәрдаим кешеләргә бу дөньяның фани булуын, адәм баласының дөньяга кунак булу һәм сыналу өчен җибәрелүен, аның һәр мизгел бакый дөньяга күчү мөмкинлеген әйтеп торган. Адәм баласы моны үзе дә күреп яшәгән.

Бүгенге көн татар халкының аңында шушы яшәүгә дошман булган вакыйга ничек гәүдәләнгән? Икенче төрле итеп әйткәндә, “**үлем**” концепты, аң берәмлеге буларак, татар телендә ничек тасвирлана?

Корпуста китерелгән мәгълүматларга караганда, татар халкының тел-аңында ул:

а) төрле исемнәр белән - *үлем, әҗәл, вафат булу, гүр иясе, дөнья кую, дөньядан китү* сүзләре белән белдерелә. *Үлем* формасы – 3625, *вафат* формасы – 4464, *әҗәл* – 433, *гүр иясе* – 284, *дөнья кую* – 350, *дөньядан китү* - 296 мәртәбә кабатлана. 45 миллионнан артык сүзне эченә алган сөйләмдә якынча 10 мең мәртәбә үлемне искә алу, бер караганда күп түгел. Әмма 45 миллион сүздән торган текстлар җыелмасы эчендә 10 – 15 миллион ярдәмлек сүзләр булуын исәпкә аласак, ул бик үк аз да түгел. “Үлем”не төрле исемнәр белән атау, мөгаен, ул сүзне күп әйтмәскә тырышуның хикмәтедер. Күңелсез ассоцияләр тудыручы сүзләрне берникадар җиңеләйтеберәк әйтү - эвфимизмнар куллану телләргә хас күренеш.

б) *үлем түшәге, үлем кочагы, үлем йокысы, үлем үзәне, үлем фәрештәсе, үлем күләгәсе, әҗәл куены, әҗәл агай* дип сөйләүләр бары тик дин йогынтысында формалашкан булырга мөмкин. Барлык өметне өзгән, газаплы, фаҗигале вакыйганы *кочак, йокы, куен, түшәк* сүзләре белән ассоциацияләү – кешене, кешелекне кайгырткан тәгълиматның – мөселман диненең күркәм сыйфаты. Шул тәгълиматкә таянып шәхес үзенең, мәрхәмәтле Ходаның шәфкате белән, мәңгелек дөньяга күчүенә соңгы минутларга кадәр өметен өзми.

в) әҗәл *Ходайдан* дигән сүзләр дин әһелләренә шулай ук кешечә яшәргә, мәрхәмәтле Аллага, бакый дөньяның барлыгына ышанып үлемтек хәзерләргә, үлүдән курыкмый, акылын җуймый дөнья белән саубуллашырга ярдәм итә.

г) Әгәр дин адәмнәрне курыкмыйча үлем каршылуга хәзерләсә, дөньяви текстлар үлемне явыз һәм газаплы бер күренеш формасында гәүдәләндерәләр. *Үлем тырнагы, үлем ачысы, үлем чире, үлем фаҗигасе, рәхимсез үлем, аяусыз үлем, котылгысыз үлем, мәрхәмәтсез үлем* кебек сүзләр бары тик адәмнең тынычлыгын югалтырга, аның үлем сәгатен якынайтырга гына мөмкиннәр.

д) *вакытсыз үлем, көтелмәгән үлем, кара үлем* кебек тасвирламалар а), б), в) өзекләрендә әйтелгәннәргә бераз каршы киләләр. Алар күп санда түгел, гаиресе бергә 19 данә, иманыбыз бераз какшагач кергән булуга охшый. Әгәр үлем ходайдан икән, ул инде вакытлы/вакытсыз да, көтелгән/көтелмәгән дә, ак/кара да була алмый.

Танылган фольклорчы В.И.Даль тарафыннан “душа народа” дип аталган мәкаль һәм әйтемнәргә күз салсак, анда да татарга мөселман дине белән иңдерелгән тыйнаклык, ризалыкларның чагылышын күрәбез. *Бирәү*

*үлә бирәү туа. Бурычтан котылып булса, әҗәлдән котылып булмый. Бәндә дөнья артыннан, әҗәл бәндә артыннан. Акча байдан, үлем ходайдан. Әҗәл кычкырып йөрми – үкчәңә басып йөри. Кешегә үлем теләгәнче үзеңә гомер телә. Үлемнән курыксаң, тизрәк үләсең. Үлемнән башка барына да ашык һ.б.*

Мәкальләрдә шулай ук татар тел ияләренең аң нигезендә яткан үлемнең тереклек дөньясына хас гадәти вакыйга булуы, дингә ышанган кеше өчен аның көтелгән һәм табигый булуы ачык чагыла.

Корпуска таянып татар халкының концептлар даирәсендә үзәк концептларның берсен тәшкил иткән **"тугрылык"** (преданность, верность) төшенчәсенә күз салыйк.

Татарча-русча, русча-татарча сүзлекләрдә бу төшенчә өч сүз – *тугрылык, турылык* һәм *туг**ъ**рылык* сүзләре белән белдерелә. Ул нигә кирәкте икән? Гәрчә телче галимнәр "турылык" сүзенә *туры* сыйфатының мәгънәсен тагуны, ә "тугрылык" сүзенә *преданность, верность* мәгънәсен тагуны якларга тиешләр иде. Ә инде "*тугрылык*" сүзенең "*туг**ъ**рылык*" формасында язылуын бары тик "башларына тай типкән" кешеләр эше дип кабул итү урынлы булыр сыман.

Язма татар телен файдаланучы шәхесләр шулай эшләгәннәр дә. Корпуска кергән текстларда исем буларак "тугрылык" формасы 717, "турылык" формасы 41, ә "тугърылык" формасы 46 мәртәбә кабатлана. Сыйфат буларак "тугрылыклы" формасы 559, "турылыклы" формасы 119, ә "ту**гъ**рылыклы"- 32 мәртәбә кулланыла.

Корпуста китерелгән мәгълүматларга таянып, татарларның тел аңында формалашкан "тугрылык" төшенчәсенең моделен төзеп күрик. Аның өчен безгә, беренчедән, татар халкының нәрсәгә һәм ни дәрәҗәдә тугрылык саклавы, икенчедән, ни дәрәҗәдә И.Даль тарафыннан "душа народа" дип аталган өлкәдә, безнең очракта, татар фольклорында урын табуы ачыкланырга тиеш була.

Корпуста урын тапкан *тугрылык, турылык, туг**ъ**рылык* исемнәренең һәм *тугрылыклы, турылыклы, туг**ъ**рылыклы* сыйфатларының сул контекстларын анализлау нәтиҗәсендә (аерым очракларда сул контекстта күзәтелгән сүзнең, үз чиратында, янә сул контексты күзәтелде) татарларның түбәндәге галәмәтләргә тугрылыклы булулары ачыкланды. Аста аларның исемлеге һәм тугрылыкка ни дәрәҗәдә лаек булуларын чагылдырган зурлыклар (процентлар) китерелгән.

а) Милли традиция һәм гореф-гадәтләргә -(18,5%),

б) Хезмәткә, һөнәргә, эшкә -(18,0%),

в) Рухи мәдәнияткә (васыятенә, мәхәббәтенә, мөселманлык рухына, халык җыры, моңы, мирасына, һ .б.) -(12,1%),
г) Исеменә, йөкләнгән бурычына (исеме, анты, сүзе, вәгъдәсенә) -(11,3%),
д) Дингә (иманга, дингә, кыйбласына, ходайга) -(9,9%),
е) Туган җиргә (илгә, ватанга, җиргә, туган ояга) -(8,8%),
ж) Милләткә (халкыбызга, җәмгыятебезгә, милләткә) -(8,3%),
з) Туганлыкка (бер-берсенә, иренә, нәселгә, туганнарына) -(5,4%),
и) Ясалма “кыйблага” (демократия, әләм, кремль, дәүләт, партиягә) -(4,0%),
к) Профессиональ сәнгатькә (сәнгать, әдәбият, шигърият, фәнгә -(3,7%).

Китерелгән процентлар татар кешесенең нәрсәгә һәм ни дәрәҗәдә тугрылыклы булуын чагылдыралар. Әйтергә кирәк, таблицада китерелгән тугрылыкка лаек булган галәмәтләрнең исемлеге дә, җәяләр эченә алынган зурлыклар да якынча мәгълүматләр тәшкил итә. Иң мөһиме, татар тел ияләре аңында “тугрылык” төшенчәсе халыкның гореф-гадәтләренә, милләтенә, туган җиренә, динебезгә бәйләнештә яши. Ул (тугрылык концепты) шулай ук татар халкының туган-тумачалыкка, нәселенә, хезмәткә, һөнәргә, дуслыкка, хакыйкатькә, ата-бабалар васыятенә, мирасына юнәлтелгән җылы хисләрен чагылдыра.

Күренекле тарихчыбыз Равил Амирхан үзенең “Иманга тугрылык” исемле китабында *Иман* төшенчәсен “Иман – иң элек Аллаһы Тәгаләгә, иллаһияткә ышану булса, икенчедән – күңел сафлыгы, рухи пакьлек, изгелек, шәфкаьлелек һәм киләчәккә якты өмет белән карау ул”- дип аңлата. Күпмиллионлы текстлар җыелмасын өйрәнеп табылган мәгълүматләр татар халкының галим әйткән сыйфатларга тугрыклы булып калуларын дәлиллиләр.

Тел ияләренең концептлар даирәсен өйрәнү – актуаль мәсьәләләрнең берсе булып тора. Беренчедән, ул укучыларны үзләренең индивидуаль концеплар даирәсен күзәтүгә этәрсә, икенчедән, милләттәшләребезнең тел аңын бераз тәртипкә салырга, сөйләүчегә фикерен тел берәмлекләренә күчерүне берникадәр шомартырга, ә тыңлаучыга аны тизрәк аңлауга ярдәм итәчәк.

20-нче йөздә лингвистика фәнендә тирән эз калдырган галимнәрнең берсе – Л. Блумфильд үзенең “Тел” исемле хезмәтен “Гәрчә хәзерге вакытта бу хыял булып күренсә дә, телне өйрәнүнең безгә ерак булмаган киләчәктә адәмнәрнең кыланышларын аңлауда, аларның кыланышлары белән идарә итүдә ярдәм күрсәтүенә без ышанабыз”, - сүзләре белән тәмамлый. (“Хотя сейчас это только мечта, можно надеяться, что в

недалеком будущем изучение языка поможет нам понимать поступки людей и управлять этими поступками”)

Бүгенге компьютерлар белән бәйләнештә телләрне өйрәнүдә ирешелгән уңышларга күз салсак, ерак булмаган киләчәкнең сизелерлек дәрәҗәдә якынлашкан булуына шик калмый. Зур телләр өчен төзелгән тезаурcallуслар, электрон корпуслар, сүзлекләр шул телләр дөньясын электрон формада компьютер хәтерендә саклауга да, аның ярдәмендә чынбарлыкта күзәтелгән вакыйгаләрне тасвирлауга да сәләтлеләр.

Инициатива күрсәтмәсәк, телебезне яңа тәгълиматләр җирлегендә яңа алымнар кулланып өйрәнүгә алынмасак, татар кыланышлары белән татарча идарә итүнең нәрсә икәнен, аның башка халыклар иркенә күчкән булуын белми дә калырбыз.

*Тәүзих Ибраһимов,*
*Мансур Сайхунов,*
*Илнар Сәлимҗанов -*
*Казан федераль университеты хезмәткәрләре.*